КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 26 апрель г.Казань № 293

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче; 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче; 2013 ел, 11 май, 313 нче; 2013 ел, 29 июнь, 455 нче; 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче; 2014 ел, 28 май, 362 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 25 август, 613 нче; 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче; 2015 ел, 4 август, 565 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1025 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 611 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 983 нче; 2017 ел, 18 май, 292 нче; 2017 ел, 27 сентябрь, 731 нче; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2017 ел, 31 октябрь, 827 нче; 2017 ел, 18 ноябрь, 885 нче; 2018 ел, 22 гыйнвар, 27 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

4 бүлектә:

4.2.8 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.8. Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә премияләр һәм бүтән бүләкләү түләүләре билге бер вакыт өчен (ай, квартал, ел), шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 30 март, б-557 нче боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау өлкәсенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән социаль өлкә тармакларындагы үзгәрешләр» чаралар планын («юл картасын») (2013 – 2018 еллар) үтәгәндә Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында юбилей даталары, күкрәк билгесе, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу белән бәйле һәм оешманың локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнгән бүтән нигезләр буенча бер тапкыр бирелә.»;

4.3.6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3.6. Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә премияләр һәм бүтән бүләкләү түләүләре билге бер вакыт өчен (ай, квартал, ел), шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 30 март, б-557 нче боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау өлкәсенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән социаль өлкә тармакларындагы үзгәрешләр» чаралар планын («юл картасын») (2013 – 2018 еллар) үтәгәндә Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында юбилей даталары, күкрәк билгесе, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу белән бәйле һәм оешманың локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнгән бүтән нигезләр буенча бер тапкыр бирелә.»;

4.4.6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.6. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә премияләр һәм бүтән бүләкләү түләүләре билге бер вакыт өчен (ай, квартал, ел), шулай ук юбилей даталары, күкрәк билгесе, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу белән бәйле һәм оешманың локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнгән бүтән нигезләр буенча бер тапкыр бирелә.»;

4.5.7 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.7. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә премияләр һәм бүтән бүләкләү түләүләре билге бер вакыт өчен (ай, квартал, ел), шулай ук юбилей даталары, күкрәк билгесе, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу белән

бәйле һәм оешманың локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнгән бүтән нигезләр буенча  бер тапкыр бирелә.»;

4.6.1 пунктта:

беренче абзацта «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары» сүзләрен «Әйдәүче буындагы мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» сүзләренә алмаштырырга;

13 таблицаның икенче юлында «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары» сүзләрен «Әйдәүче буындагы мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» сүзләренә алмаштырырга;

4.6.7 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.7. Мәдәният өлкәсе хезмәткәрләренә премияләр һәм бүтән бүләкләү түләүләре билге бер вакыт өчен (ай, квартал, ел), шулай ук юбилей даталары, күкрәк билгесе, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре  алу белән бәйле һәм оешманың локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнгән бүтән нигезләр буенча  бер тапкыр бирелә.»;

4.7.6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7.6. Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә премияләр һәм бүтән бүләкләү түләүләре билге бер вакыт өчен (ай, квартал, ел), шулай ук юбилей даталары, күкрәк билгесе, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре  алу белән бәйле һәм оешманың локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнгән бүтән нигезләр буенча  бер тапкыр бирелә.»;

7 бүлектә:

7.5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$FOT_{or}$ – вазыйфаи окладларны түләүгә, әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән стимуллаштыру (әлеге Нигезләмәгә 2 нче һәм 4 нче кушымталарда каралган, сумма чагылышында билгеләнгән түләүләрдән тыш) һәм компенсацияләү характерындагы (әлеге Нигезләмәгә 12 нче һәм 13 нче кушымталарда каралмаган хезмәтнең зарарлы һәм (яки) куркыныч шартлары өчен түләүләрдән тыш) түләүләргә каралган хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү фонды;»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары  эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

3 бүлектә:

3.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.15. Төп эш урыны буенча  хезмәткәрләргә премияләр һәм бүтән бүләкләү түләүләре билге бер вакыт өчен (ай, квартал, ел), шулай ук юбилей даталары, күкрәк билгесе, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре  алу белән бәйле һәм

оешманың локаль актлары һәм кумәк шартнамәләр белән билгеләнгән бүтән нигезләр буенча  бер тапкыр бирелә.».

2. Бу карарның гамәле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең 7 бүлегенә кертелә торган 2018 елның 1 февраленнән үз көченә керә торган үзгәрештән тыш, 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин